СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

23.10.2020 17

Баулы муниципаль районы Советының
2018 елның 13 декабрендәге «Баулы
муниципаль районында вакантлы
муниципаль хезмәт вазыйфасын
биләүгә конкурс уздыру тәртибе
турындагы нигезләмәне раслау хакында»
188нче номерлы крарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 13 декабрендәге «Баулы муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 188нче номерлы карары (2019 елның 27 мартындагы 203 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8нче пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр (хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советы рәисе урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе                                        Р.Х. Гатиятуллин